ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29 август 2018ел № 4821

Яр Чаллы шәһәренең «Чаллы» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 17 маддәсе 1 бүлеге 4 пункты, шәһәр Уставының 41 маддәсе, Шәһәр Советының «Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакындагы нигезнамәне раслау турында» 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 нче карары, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 нче карары белән расланган Муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турындагы нигезнамәгә туры китереп

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «Чаллы» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.
2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастыруны һәм Татарстан Республикасының (pravo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүмат рәсми порталында, «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2018 елның 29 августындагы
4821 нче карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең «Чаллы» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар

| Т/с | Тукталышка кую төре | Автотранспортның маркасы | Үлчәү берәмлеге | Бәясе, сум |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Көндезге | Җиңел автомобиль/автобус | Бер сәгатькә машина урыны | 20/30 |
| 2. | Тәүлек буе | Үзебезнең илдә эшләнгән автомобильләр (ОКА, ВАЗ, Волга, Москвич) | Бер айга машина урыны | 800/900 |
| 3. | Төнге (бер тапкыр, 18.00 дән 8.00 сәгатькә кадәр) | Үзебезнең илдә эшләнгән автомобильләр (ОКА/ ВАЗ, Волга, Москвич) | Бер сәгатькә машина урыны | 40/50 |
| 4. | Тәүлек буе | Чит илдә эшләнгән автомобильләр | Бер айга машина урыны | 1000 |
| 5. | Төнге (бер тапкыр, 18.00 дән 8.00 сәгатькә кадәр | Чит илдә эшләнгән автомобильләр | Бер сәгатькә машина урыны | 50 |
| 6. | Тәүлек буе | Газель, автобус, ПАЗ | Бер айга машина урыны | 2000 |
| 7. | Төнге (бер тапкыр, 18.00 дән 8.00 сәгатькә кадәр | Газель, автобус, ПАЗ | Бер сәгатькә машина урыны | 80 |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Г.К. Әхмәтова